Татарстан Республикасы Әтнә районы муниципаль районы

Күлле-Киме авыл җирлеге Советы карары

03.10.2019 ел № 106

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 ноябрендә кабул ителгән 80 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында " карарына үзгәрешләр кертү турында».**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 ноябрендәге 80 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» (2015 елның 3 июнендәге 105 номерлы, 2015 елның 19 октябрендәге 4 номерлы, 2018 елның 2 июлендәге 76 номерлы , 2019 елның 9 мартындагы 90 номерлы, 2019 елның 22 апрелендәге 96 номерлы редакциясендә) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктта: 2 нче пунктчага «фатир» сүзеннән соң « фатир өлешләреннән " сүзләрен өстәргә;» 3 нче пунктчага " торак йортлар» сүзләреннән соң “торак йортларның өлешләре”; сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Этнә таңы» район газетасында, мәгълүмат стендларында, http://atnya.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында һәм pravo.tatarstan.ru .рәсми сайтында бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карар 2020 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча һәм 2017 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы: Гараев Х.Х.